## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Чукмарлы авыл жирлегенең Чукмарлы авылы торак пунктында
2022 елда үзара салым кертү турында

**15 ноябрь, 2021 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенең Чукмарлы авылында граждannар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге Чукмарлы авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидларыннан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Зират территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү, Чукмарлы авылы зираты ое өчен төзелеш материаллары сатып алу;

- Чукмарлы авылы урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм хезмәт күрсәтү (лампалар,энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);

- Чукмарлы авылында мәдәни чаралар уздыру өчен бүләкләр алу (Сабантуй, өлкәннәр көне, 9 Май);

-Беларусь 82.1» тракторы өчен КУН-10 төягече сатып алу;

-« Чукмарлы авылында «Беларусь 82.1» тракторын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, һәм машина йөртүче хезмәте өчен түләү);

-Бензин чапкычлары өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу

3. Әлеге карарны Чукмарлы авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка житкерергә, Сарман муниципаль районының

рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Чукмарлы авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче И.Х.Хадиуллин